МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№________________

На №_______________от________________

**Руководителям отделов (управлений) образования исполнительных комитетов муниципальных образований Республики Татарстан**

О проведении IV республиканской научно-практической конференции им. М.Джалиля

**Уважаемые руководители!**

В целях развития творческого потенциала обучающихся, выявления одарённых и талантливых школьников для последующей поддержки и развития их способностей, систематизации знаний о жизни и творчестве легендарного поэта Мусы Джалиля, Министерством образования и науки Республики Татарстан совместно с Управлением образования Исполнительного комитета Балтасинского муниципального района 17 февраля 2017 года проводится IV республиканская научно-практическая конференция имени Мусы Джалиля (далее – Конференция).

В Конференции могут принять участие обучающиеся 8–11 классов общеобразовательных организаций Республики Татарстан. Для участия в Конференции необходимо направить заявку, научно-практические и творческие работы в срок до 1 февраля 2017 года в оргкомитет МБОУ «Карадуванская гимназия им. Б.Зиатдинова» Балтасинского района по почтовому адресу: 422261, Республика Татарстан, Балтасинский район, д. Карадуван, ул. Сибирский тракт, д. 51 или на электронный адрес npk.2014@mail.ru с пометкой «Конференция» и указанием фамилии автора.

Командировочные расходы производятся за счет направляющей стороны.

Ответственность за жизнь и здоровье школьников в пути следования и во время мероприятия необходимо возложить на сопровождающих педагогов.

Место проведения: МБОУ «Карадуванская гимназия им. Б.Зиатдинова». Адрес проведения: Балтасинский район, д. Карадуван, ул. Сибирский тракт, д. 51.

Телефоны для справок: 8 (84368) 3 21 19, 8 (84368) 2 41 95.

Приложение: на 3 л. в 1 экз.

**Заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр** **Э.Н.Фаттахов**

Л.Р.Зайнуллина
(843) 294 95 10



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Приложение

**Муса Җәлил исемендәге IV республика фәнни-гамәли конференция НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## I. Гомуми мәгълүмат

1.1. Әлеге нигезләмә патриот шагыйрь Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты - Муса Жәлил исемендәге республика фәнни-гамәли конференциясен (алга таба – Конференция) үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конференция Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 72 еллыгы, Муса Жәлил тууына 111 ел тулу уңаеннан үткәрелә.

## II. Конференциянең максаты һәм бурычлары

Конференция татар әдәбиятын, мәдәниятен һәм Муса Жәлилнең иҗатын тирәнтен өйрәнү, пропагандалау һәм популярлаштыру максатыннан үткәрелә.

Конференциянең бурычлары:

- укучыларда фәнни-тикшеренү күнекмәләрен формалаштыру;
- бүгенге көн укучысында әхлак, әдәп идеалларын билгеләү;
- халкыбызның милли үзенчәлекләре, күркәм сыйфатлары, аның батыр уллары турында сөйләп, укучыларны өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләү, буыннар бәйләнешен тәэмин итү;
- гомумкешелек кыйммәтенә аңлы караш тәрбияләү;
- фәнни эзләнүләрендә иҗадилыкка омтылышларын булдыру;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру.

## III. Конференцияне оештыручылар

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Балтач районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе;
- Карадуган «Себер тракты тарихы» музее;
- Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе «Бакый Зыятдинов исемендәге Карадуган гимназиясе».

## IV. Конференциядә катнашучылар

Конференция эшчәнлегендә гомуми белем бирү учреждениеләренең 8-11 нче сыйныф укучылары катнаша ала.

## V.Конференцияне үткәрү шартлары һәм тәртибе

Конференция **2017 елның 17 нче февралендә** Балтач муниципаль районы Бакый Зыятдинов исемендәге Карадуган гимназиясендә үткәрелә.

Конференция 2 этапта үтә.

I этап - сайлап алу (читтән торып) **2017 нче елның 1 нче февраленә кадәр.** Эшләр (**язмача** һәм **электрон** вариантта) заявка белән бергә **2017 елның 1 нче февраленә** кадәр Карадуган гимназиясенә 422261, Татарстан Республикасы, Балтач районы, Карадуган авылы, Себер тракты, 51 почта адресы яисә npk.2014@mail.ru электрон почта адресына җибәрелә. Хезмәтләр татар телендә булырга тиеш. Текстның күләме 8-10 басма биттән артмаска тиеш. Эзләнү эшендә күрсәтмә материаллар (рәсем, схема һәм карта, таблица, фоторәсемнәр) булырга мөмкин.

Документ создан в электронной форме. № исх-3398/16 от 31.12.2016. Исполнитель: Зайнуллина Л. Р.
Страница 2 из 5. Страница создана: 29.12.2016 17:37
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

II этап - оештыру комитеты тикшергәннән соң, уңышлы дип табылган эш авторлары **2017 елның 17 нче февралендә** Карадуган гимназиясенә фәнни-гамәли конференциягә чакырыла. Укучы үзе сайлаган темага чыгыш әзерли (эзләнү эше, реферат, доклад, эксприменталь материал булырга мөмкин). Икенче турга үткән укучыларның исемлеге Карадуган гимнязиясенең сайтына эленә (https://edu.tatar.ru/baltasi/karaduvan/sch), өстәмә хат юллана.

Конференциядә чыгыш ясау вакыты 3-5 минут. Укучы шушы вакыт эчендә эчтәлекне ачып, төп фикерене әйтеп бирә белергә тиеш (компьютер презентациясе хуплана).

## VI. Конференцияне оештыру һәм үткәрү тәртибе

Эшләр түбәндәге юнәлешләрдә кабул ителә:

1. Авылым Бөек Ватан сугышы елларында (мәктәп музейлары эшчәнлегенә нигезләнгән булуы шарт).
2. «Күңел җылым – хатларда» (татар язучыларының сугыш чоры хатлары).
3. Муса Җәлил әсәрләренең тел һәм стиль үзенчәлекләре.
4. Җәлил премиясе лауреатлары турында эзләнү эшләре (җирле материал белән бәйләнештә).

Фәнни-гамәли эшләргә таләпләр:

Эш төзәтүләрсез А4 форматында (шрифт Times New Roman - 14, интервал – 1.5, уңнан - 1.5, сулдан - 2.5, астан - 2, өстән - 1.5) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла.

Фәнни эш кабул ителгән стандарт кысаларында билгеле бер структурага нигезләнеп үтәлә. Титул бите, эчтәлек, кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлеге, кушымта кебек өлешләрдән тора.

Титул битенә гомуми белем бирү оешмасының тулы исеме, шәһәр, район, укучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, тема, эшнең юнәлеше һәм укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

Фәнни эш үтә күренмәле тышлы папкага урнаштырылып, 1 данәдә тапшырыла.

Конференциягә башка конкурсларда, конференцияләрдә катнашып, призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.

Фәнни эшләр, чыгышларны бәяләү өчен критерийлар:

- сайланган теманың яңа, актуаль булуы;
- эшнең фәннилеге;
- проблеманы чишүнең тирәнлеге, тулылыгы;
- әлеге тема буенча эшләүче галимнәрнең фикеренә таяну;
- эшләрнең җирле материалларга нигезләнгән булуы;
- эшнең максатын дөрес билгеләү;
- логик яктан дөрес фикерләү, дәлилләнгән нәтиҗәләр ясау;
- чыгышның композицион бөтенлеге, дәлилле булуы, теманың тулы ачылуы;

- чыгыш ясаучының аралашу культурасы;
- жюри әгъзалары биргән сорауларга җавап бирү дәрәҗәсе.

## VII.Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

Катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.

Эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла.

Эксперт комиссиясе карары турында беркетмә языла.

1 нче этапта катнашкан барлык укучыларга Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсенең сертификатлары тапшырыла.

2 нче этапта чыгыш ясаучыларга Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының сертификатлары, җиңүчеләргә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының дипломнары тапшырыла.

Белешмәләр өчен телефоннар:

Карадуган гимназиясе 8(84368)32119

сайт https://edu.tatar.ru/baltasi/karaduvan/sch

Балтач районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе 8(84368) 2 41 95

## Муса Җәлил исемендәге IV республикакүләм фәнни-гамәли конференциядә катнашу өчен Гариза үрнәге

| № | Укучының исем-фамилиясе, әтисенең исеме | Район, мәктәп, класс | Хезмәтнең темасы | Кайсы секциягә тәкъдим ителә (эш юнәлешләре) | Житәкченең исем-фамилиясе, әтисенең исеме | Элемтә өчен кәрәзле телефон номеры (укучыныкы, җитәкченеке) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № исх-3398/16 от 31.12.2016
Инициатор согласования: Зайнуллина Л. Р. Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 29.12.2016 17:38

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано 30.12.2016 - 09:09 | - |
| 2 | Исмагилова Г.Х. | | Согласовано 30.12.2016 - 11:19 | - |
| 3 | Мухаметов И.Р. | | Согласовано 30.12.2016 - 23:15 | - |
| 4 | Фаттахов Э.Н. | | Согласовано 31.12.2016 - 07:21 | - |